**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.02.2018 Балык Бистәсе штп. № 24пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Россия Пенсия фонды Идарәсе тәкъдимен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пунктын, 12 статьясындагы 3 пунктын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең«2018 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2018 елның26 гыйнвардагы 74 номерлы карарының 3 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 46 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә 2018 елның 1 февраленнән 1,2 номерлы кушымталар нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 5701,31 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»2017 елның 1 гыйнварындагы 19пи номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Р. Хисмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Таҗетдинов

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018
елның 09 февралендәге № 24пи
карарына  кушымта№1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне тәэмин итү һәм җибәрү | 1607 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) китерү | 889 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм җирләү  ) | 3205,31 |
| Барлыгы: | 5701,31 |